Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№31 (124)

30 октябрь 2014 ел



Влад Михневский фотосы

# Сәхнә түрендә – безнең лаеклы киләчәк!

Узган атнаның шимбәсендә «УНИКС» концертлар залында беренче курс студентлары КФУның лаеклы киләчәге булачакларын тагын бер кат исбатладылар. «Беренче курслар – 2014» Гала-концертында яңа буын бөтен сәләтен күрсәтеп, сөйләп, дәлилләп бирде. Жюрига иң яхшылар арасыннан тагын да яхшыракларны сайлап алырга кирәк иде. Җиңүчеләр өч төркемгә бүленеп билгеләнде. Беренче төркем җиңүчесе – Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты. Икенче төркемдә иң яхшы дип Юридик факультет сайланды. Өченчедә исә – Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты. Фестивальнең гран-при иясе – Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты. Афәрин, беренчеләр!

Әшлекле сөйләшү

# «Баш, ручка һәм компьютер гына кирәк!»

Әңгәмәдәш **Алинә САДЫЙКОВА**

Хәзерге дәвердә көн саен нинди дә булса үзгәрешләр булып тора һәм алар, әлбәттә, уку процессында да чагылыш тапмый кала алмый. КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институты да яңа уку елын зур үзгәрешләр белән башлап җибәрде. Бу уңайдан аның директоры, профессор Наилә Баһаветдинова белән әңгәмә кордык.

**– Наилә Гомәровна, сез университетыбызның иң эре институтларының берсен җитәклисез. Структурагыз турында тулырак сөйләгез әле.**

- Университетыбызның Гыйльми Советы утырышы карары нигезендә, Идарә һәм территориаль үсеш институты белән Икътисад һәм финанслар институты берләштерелде. Хәзер без күпкырлы һәм эре структурага әверелдек. Институтыбызның фәнни житәкчесе булып, ректорыбыз **И.Гафуров** тора. Бүгенге көндә бездә 5 бүлек: гомум икътисади, менеджмент, предприятиеләр икътисады, финанслар бүлеге һәм территориаль икътисад бүлекләре бар Бу, үз чиратында, 27 кафедра, 2 лаборатория, 3 югары мәктәп, 7600 студент, 120 аспирант дигән сүз. Уку процессы бакалавриатның 13 юнәлеше һәм төрле программаларның 33 профиле буенча башкарыла. Магистратурада 25 программа бар, шуларның 2се инглиз телендә алып барыла. Без инде хәзер бер бинага гына сыймыйбыз, шуңа институтыбызга 3 кампус бүлеп бирелде.

**- Ике институтны берләштерүгә ничек карыйсыз?**

- Бу бик күңелле процесс булмаса да, закончалыклы күренеш. Ник дигәндә, параллель, кисешә һәм кабатлана торган белгечлекләр бик күп иде. Хәзер исә менеджмент, икътисадтагы матметод, финанслар, икътисади дисциплина, икътисад теориясе кебек фәннәр барысы да безнең институтта тупланды. Шуңа күрә, өметләребез һәм планнарыбыз бик зурдан.

**- Институтның белем бирү процессында иң төп максаты нинди?**

- Без университетның иң эре социаль-икътисади блокларының берсенә керәбез, шуңа да әлеге исемгә лаек икәнлегебезне һәрдаим исбатлап торырга кирәк. Без, һөнәри күнекмәләргә генә өйрәтеп калмыйча, фәнгә аерым басым ясарга тырышабыз. Моның өчен теге яисә бу өлкәдә һөнәри эшчәнлек алып барган белгечләрне җәлеп итәбез. Шулай ук база кафедраларын, социаль-икътисади блокта OpehLabлар булдырасыбыз килә. Фәнне аспирантура аша гына үстереп калмыйча, аны заман таләп итә торган тиешле авырлыкта һәм күпкырлы итеп күрәсе килә.



**- Моның өчен нинди чаралар кулланасыз?**

- Беренче чиратта, без заманча технологияләр белән эш итәбез. Лекцияләрне дәфтәр битеннән укып, студентларга яздырта торган көннәр артта калды инде. Дәресләрне күбрәк презентацияләр белән, кызык һәм үтемле, укучыларның үзләрен җәлеп итеп үткәрергә тырышабыз. Безнең беренчел максат: аларны тикшеренүче һәм прогнозлаучы итеп җитлектерү. Бу студентларның үзләренә дә бик ошый. Ул бик җиңел эш түгел: рубль, долларның күпме торганын модельләштерү, теге яисә бу финанс агымының тормышка ничек тәэсир итүен, теге яки бу санкцияләрнең төбәк, шәһәр, илнең икътисадында ни рәвешле чагылыш тапканын билгеләү һ.б. Ягъни, монда аерым бер лаборатория, бахиллар, химик препаратлар кирәк түгел. Биредә бары тик баш, ручка һәм компьютер гына кирәк. Бу иң мөһиме!

**- Сез әзерли торган белгечлекләрнең хезмәт базарында аеруча кайсыларына сорау күп?**

- Без әзерли торган барлык белгечлекләр дә бик кирәкле. Банк хезмәткәрләре, финансистлар дисеңмә. Мисал өчен, эре консалтинг компанияләре безнең бухучетны тәмамлаучыларны көтеп кенә торалар, менеджерларыбыз төрле дәрәҗәдәге идарә хезмәткәрләре булып эшли. Кыскасы, кайсы гына белгечлекне алсаң да, аларны югары бәялиләр. Бу аңлашыла да: алар илебездәге иң яхшы уку йортларының берсе булган КФУны тәмамлаучылар бит!

**- Сезнеңчә, ни өчен абитуриентлар нәкъ менә сезнең институтны сайлый?**

- Миңа калса, бу кешеләрнең тизрәк бай булу теләгенә бәйле. Бездә шулай бит инде: әгәр акчаның ни икәнен һәм аның белән эшли белсә, кеше уңышлы исәпләнә. Шуңа да кешеләр финанс агымнары һәм чыганакларына якынрак булырга тырышалар. Укуга килгәндә, җиңел дип әйтмәс идем. Әлбәттә, бездә сопромат, физика һәм анатомияләр юк, шулай да уйларга мәҗбүр итә торган икътисади дисциплиналар бик күп.

Очрашулар

# Күңелле яшибез

**Гөлфиназ НӘБИУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Шушы көннәрдә Милли китапханәдә бик талантлы шәхес, Г.Камал театры артисты Хәлим Җәләлов белән очрашуда катнашырга насыйп булды.



Менә җәт-җәт кенә Хәлим Җәләлов үзе килеп керде. Кемгәдер күпләр яратып караган спектакль герое Шәкүр, кемгәдер талантлы артист, кемгәдер нәфис сүз остасы, кемгәдер укытучы, остаз, ә кемгәдер яхшы якын дус...

Иң элек аңа китапханә директоры Наил әфәнде иң зур бүләкләрнең берсен – китап тапшырды. Шул уңайдан, аның үзе язган китаплары белән дә танышып киттек. Хәлим абыйның яшел тышлы дәфтәре дә бар икән. Нинди дәфтәр дисәгез, ул анда үзенең иң яраткан шигырьләрен җыеп бара һәм ул дәфтәрләр дә берәү генә түгел. Заманында: «Синең шигырь шигырьмени Җәләловның яшел дәфтәренә дә кермәгәч», – дип шаярта торган булганнар. «Безнең заман – шигъри заман иде. Без Тукай клубларында тәрбияләндек. Бездә китапка ихласлылык көчле иде. Кая барсак та, шигырьләр сөйли идек, алар турында дискуссияләр алып бара идек.Минем әткәй дә шигырьләр яраткан. Тукай шигырьләрен сөйләп, амбарда хатын-кызлар көлдереп йөри иде, дип сөйли иде әнкәй», – дип, артист күңел сандыгында сакланган хатирәләре белән уртаклашты.

Аның белән бик күп еллар эшләгән хезмәттәше, Камал театрының олы буын артисты Әсхәт Хисмәтовның зур осталык белән башкарылган «Әрем исе, әрем тәме» җыры килгән кунакларны уйланырлы, моң дигән сихри дәрьяларга алып китте.

Кичә барышында Хәлим абый катнашында спектакльдән кызыклы өзекләр дә уйналды. Шигырь белән башланган кичә шигырь белән тәмамланды. Кичә тәмамлангач, Хәлим абыйның театр афишасына автограф куйдырырга һәм истәлеккә фотога төшәргә дә мөмкин булды. Ни дисәң дә, бер күрешү – үзе бер гомер бит!

Без, Г.Тукай ис. татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең 5нче курсын тәмамлап, тагын берничә айдан татар теле һәм әдәбияты укытучылары буласы студентлар, төп белгечлектән тыш, өстәмә рәвештә журналистика белгечлеген дә үзләштерәбез. Әлбәттә, университетта уку елларында төп юнәлештә тирән һәм киңкырлы белем алып, мәктәпләрдә унышлы гына узган практикадан соң, күбебез инде үзебез өчен укытучы булу мәсьәләсен хәл итеп куйган идек. 23 октябрьгә кадәр нәрхәлдә...

# «Ватаным Татарстан»да кунакта

**Лилия ЯКУПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты




Ошбу көнне, «Ватаным Татарстан» редакциясенә сәяхәт кылып кайтканнан соң, безнең күңелләрдә үзгәрешләр барлыкка килде, икеләнүләр туды. Тәртип белән баштан башлыйм әле.

Билгеләнгән вакытта укытучыбыз Таһир Шәмсегали улы Гыйләҗев җитәкчелегендә «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясенә юл тоттык. Әлеге газетаның баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров белән инде танышлык бар, чөнки күптән түгел генә уку йортыбыз бинасында кызыклы очрашу оештырылган иде. 27 ел гомерен журналистик эшчәнлегенә багышлап, зур тәҗрибә туплаган һәм гаҗәеп дәрәҗәдә кешелекле, киң күңелле Миңназыйм абыйны без бик тиз үз иттек, укытучыбыздай якын күрдек.

«Ватаным Татарстан» редакциясе «Татмедиа» бинасында урнашкан, биредә ул «Республика Татарстан» газетасы белән күршелек итә, һәр ике коллектив үзара дус һәм тату яши, эшли. Безнең килү хезмәткәрләр тарафыннан табигый кабул ителде, һәр җирдә ачык йөз белән каршы алдылар, хәтта истәлекле бүләкләр белән зур хөрмәт күрсәтеп озаттылар. Ә без, үз чиратыбызда, редакциядәге һәр бүлекнең эшчәнлеге белән танышып, «Ватаным Татарстан» газетасының «дөньяга килү» процессын үз күзләребез белән күрдек. Әйтик, хатлар, хәбәрләр, дизайн бүлекләренең вазифалары төрле, һәр журналистның үз сәхифәсе, эш юнәлеше бар. Редакциядәге матур мохит, үзара кешелекле һәм җылы мөгамәлә безне сокландырды.

Моңа кадәр рәшә сыман гына тоелган журналист эшчәнлеге, аның көндәлек бурычлары, вазифалары үзеннән-үзе ачыклана барды. Күңелдә кызыксыну, үзеңне сынап карау теләге туды. Ә нигә, бәлки, журналистика чыннан да безнең өлкәбез, киләчәгебездер?! Уйлап бетерү, нәтиҗәләр ясау өчен нибары ярты еллап вакыт калып бара. Уку йортыбыз бусагасын атлап чыккач, юл-һөнәр сайлау мөмкинлеге – безнең кулларда.

Ә без, үз чиратыбызда, мондый кызыклы очрашуларны оештырган хөрмәтле остазыбыз Таһир Шәмсегали улына һәм бик теләп очрашуларга килгән, җавап рәвешендә редакциягә кунакка чакырган «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Миңназыйм абый Сәфәровка ихлас күңелдән рәхмәт белдерәбез! Күңелдә бары бер теләк: киләчәктә Сезгә лаек алмаш булырлык белемле, киң эрудицияле шәхесләр була алсак иде.

Юбиляр

# Гыйлеменә карап шөһрәте

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,** Укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе, профессор

СОҢГЫ ЕЛЛАР ТУДЫРГАН ИҢ ЗУР ПРОБЛЕМАЛАРНЫҢ БЕРСЕ – ПЕДАГОГИК ПРОБЛЕМА. ӘЙЕ-ӘЙЕ, МОНЫ ӘЛЕ БАРЛЫК ТИРӘНЛЕГЕ, БАРЛЫК НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ БЕЛӘН КҮРЕП-КҮЗАЛЛАП БЕТЕРҮ ГЕНӘ ҖИТЕНКЕРӘМИ.

Рухи кыйммәтләр кискен алышынган, «базар мөнәсәбәтләре» дип аталган күренеш яшәү рәвешебездә тамыр җәя барган бер заманда тәрбия мәсьәләсе, педагогик таләпләр ничектер арткы бер планга күчте кебек. Әмма педагогика – яшәешнең асылына нигезләнгән, борынгыдан ук тамырланган фән. Җәмгыять төзелеше ничек кенә үзгәрмәсен, кеше шәхесен тәрбияләү мәсьәләсе, педагогик проблемалар яшәешебезнең үзәгендә торачак. Җәмгыятебез аларның мөһимлеген ни дәрәҗәдә аңлый, ни дәрәҗәдә һәм ничек хәл итәргә омтыла – андагы тормыш, яшәеш һәм көнкүреш дәрәҗәсе дә шуңа карап билгеләнә. Менә шушы табигый хакыйкатьне дөрес аңлаган шәхесләрнең берсе – күренекле галим, профессор **Җәмил Газиз улы Нигъмәтов** турында сөйлисем килә.

Укытучы – киләчәк буынга нигез салучы. Укытучы эшчәнлеген иң авыр хезмәтләрнең берсе дип саныйм мин. Чөнки киләчәк буынны илгә-көнгә файдалы итеп тәрбияләү алар кулында бит. Яраткан язучыбыз Фәнис абый Яруллин укытучылар турында мондый юллар язган:

*Килгән чакта башка авырлык,*
*Җитми калса көч я сабырлык,*
*Сиздермичә ярдәм иткәнсез,*
*Сез иң гүзәл кеше икәнсез!*

Нәкъ менә шундый шәхесләрнең берсе, укытучыларның укытучысы – ул Казан федераль университетының укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы профессоры, Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Җәмил Газиз улы Нигъмәтов. Бу урында башта шуны билгеләп үтү мөһим: XXI гасырга аяк баскан бер чорда, илебезнең мәгариф тармагы үсешкә ирешүнең төрле юлларын эзли. Мәгълүм булганча, «коммунистик киләчәк» идеяләре таркалды һәм мәгърифәтебез дә социаль мохиттә ирекә чыкты. Кызганыч, безнең җәмгыять мәгариф өлкәсендә ачык идеаллары булган юнәлешләр таба алмады әле. Әмма мәктәп идеалларсыз яши алмый, ул үзенең тәрбияләнүчеләренә тулы мәгънәсендә остаз булырга, аларга тиешле дәрәҗәдә ачык һәм лаеклы булган максатларны күрсәтергә тиеш. Педагогик белем бирү системасы һәм фәнебез белем бирү һәм тәрбиянең алдагы максатларга ирешү ысулы булуын тәэмин итәргә тиеш. Бу җәһәттән мәгариф проблемалары белән дистә еллар дәвамында шөгыльләнүче галим-педагог Җәмил аганың хезмәтләрен бәяләп үтү зарурдыр, мөгаен.

Галимнең педагогик эшчәнлеге үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм аңа белем бирү, педагогик кадрлар әзерләү, шулай ук Ватаныбыз педагогикасының гуманистик традицияләрен өйрәнүгә багышлана. Ул тәрбияләп үстергән галимнәр үзләренең ныклы теоретик әзерлекле, югары һөнәри осталыкка һәм оештыру сәләтенә ия булулары белән аерылып торалар.

Барыбызга да мәгълүм: хәзер Русия мәгарифен үзгәртүдә төп юнәлеш – гуманлаштыру. Узган гасырның 80нче еллар башыннан профессор Нигъмәтов бу проблеманың киләчәк мәктәбе өчен перспективалы булуына инанган, әйдәп баручы тикшеренүчеләрнең берсе иде. Русия Федерациясендә беренче булып әлеге проблема буенча докторлык диссертациясе яклады, шул рәвешле, гуманлаштыру тәгълиматын хәзерге заман педагогика теориясендә төп фәнни юнәлеш буларак танытты.

Ул мәктәптәге укыту-тәрбия процессын гуманизм идеяләре белән сугаруның тулы бер концепциясен тәкъдим итте. Бу җәһәттән аның «Мәгариф тарихы һәм фәлсәфәсе» дигән лекцияләр курсы да дөнья күрде. Әлеге китап буенча без мәгарифнең барлыкка килүе һәм үсеше, колбиләүчелек, феодаль җәмгыятьләрдә, монополистик капитализмга кадәрге чорда, француз буржуаз революциясе чорында тәрбия, мәктәп һәм педагогик фикерләр турында бик күп нәрсәләр белдек.

Җ.Г.Нигъмәтов – Татарстанда гына түгел, илдә, дөнья күләмендә яхшы танылган галим. Югары мәктәп даирәләре тарафыннан галимнең укыту-тәрбия процессына актив рәвештә кертелгән фәнни эшкәртмәләре инде күптән югары бәяләнде. Профессорның гуманлылык концепциясе югары һәм урта уку йортларында укыту-тәрбия процессын гуманлаштыру һәм гуманитарлаштыру программасының нигезе булып тора. Галимнең идеяләре Татарстан һәм Идел буе югары уку йортларында аеруча актив кулланыла.

Мәктәп тормышы гуманистик идеаллар һәм мөнәсәбәтләр белән тулысынча сугарылган булырга тиешлеген бүген исбатлап тору кирәк түгелдер, мөгаен. Барыбызга да билгеле: хәзер Русия мәгарифен үзгәртүдә төп юнәлеш – гуманлаштыру. Ләкин Совет мәктәбе тарихы гуманлылыкның чамасыз коммунистик инанганлык тәрбияләү белән чагыштырганда, күпкә түбән дәрәҗәдә булган вакытларны хәтерли әле. Укучыларны гуманлы нигездә тәрбияләү проблемаларын сайлау актуаль түгел дип әйтелгән заманнар да булган хәтта. Шулай да, бәхеткә, педагогика фәнендә тикшеренүче-педагогларны тәрбияләүдә гуманлылык проблемалары белән кызыксынучыларга кытлык булмады. Профессор Нигъмәтовның бу өлкәдә лидер, әйдәп баручы булуын билгеләп үтү гаять мөһим. Ул мәктәпнең укыту-тәрбия процессын гуманизм идеяләре белән сугаруның тулы бер концепциясен тәкъдим итте. Моңа проблеманы һәрьяклап: тарихи-мәдәни, антропологик, социаль, психологик һәм педагогик яктан тикшеренүнең теориясен эшкәртү алшарт булып торды да инде. Һәм бу гуманлылык принцибының реаль эчтәлеген мәктәп эшчәнлегенең тере чыганагы буларак тану өчен чын фундаменталь теоретик база булдырырга ярдәм итте.

Җ.Нигъмәтовның бу юнәлештәге эшчәнлеге аның күп санлы фәнни хезмәтләрендә (250дән артык басма), ул оештырган халыкара дәрәҗәдәге берничә фәнни-тәҗрибә конференция материалларында (14 конференция) ачык чагыла. Югары мәктәп даирәләре бу галимнең укыту-тәрбия процессына актив рәвештә кертелгән фәнни эшкәртмәләрен инде күптәннән югары бәяләде. Профессорның фәнни казанышлары киң танылуын аның хезмәтләренең күп кенә чит ил фәнни җәмәгатьчелегенә дә яхшы билгеле булуы күрсәтә.

Галимнең киләчәк заман мәктәбен күз алдына китерүе кызыклы. Бу нисбәттән аның «Мәктәп белән идарә итүдә кафедра формасы» дигән хезмәте мәктәптә аерым фәннәр буенча кафедралар булдыруны күз алдында тота. Бу юнәлештә ул Казанның 11нче мәктәбендә әле 1998 елда ук эш башлап җибәргән. Биредә IX сыйныфларда математиканы инглиз телендә укыту оештырылган. Аннары, шулар арасыннан 15 укучыны сайлап, математиканы инглиз телендә тирәнтен өйрәтә башлаганнар.

Җәмил Газизович, физматта иң көчле студентлардан бер төркем туплап, чит тел дәресләре урынына математиканы инглиз телендә укыта. Студентлар дәресне инглиз телендә алып барырлык дәрәҗәгә ирешергә тиеш. Максат шундый. Бу галимнең иң зур хыялларының берсе.

Аның төп иҗат урыны булып, сүз дә юк, Казан федераль университеты тора. Нәкъ менә шунда ул мәгарифне гуманлаштыру өлкәсендә тикшеренүләрнең зур гына фәнни мәктәбен оештыра алды. Шушы мәктәп эчендә бербөтен Русия мәктәбе һәм, гомумән, төбәк мәктәбе үсеше өчен зур табыш китергән күп кенә кызыклы эзләнүләр уңышлы алып барыла да инде.

Галим мәктәпләр белән элемтәне бүген дә өзми: аның өчен яңа фәнни концепцияләр төзи, мәктәпләрдә һәм гимназияләрдә бик еш була. Шулай ук ул югары уку йортларының мәктәпләр белән кулга кул тотынып эшләүләрен хуплый, чөнки бүгенге студентларның иртәгә белем һәм тәрбия бирәчәген алдан күреп эш итә. Ул үз хезмәтен канатланып, бик теләп башкара. Аның әле дә фән үрләрен яулау омтылышы сүнми. Галим һәрдаим үзенең энергиялелеге, активлыгы һәм эш сөючәнлеге белән аерылып тора.

Профессор бүгенге җәмгыятьтәге әхлаксызлык күренешләренә нык борчыла. Әхлаксызлыкның нигезе – кешенең табигать дөньясыннан аерылган булуында, дип күрсәтә ул. Шуңадыр инде, аның матбугатта даими басылып килә торган фәнни хезмәтләре дә шул рухта сугарылган. Булачак укытучыларга да укучыларга ничек якын килергә кирәклеген аңлата, төшендерә, гамәли яктан күрсәтә.

Ныклы ихтыяр көче, хезмәт сөючәнлеге, аек акылы, эзләнүчән холкы, эшчәнлеге үзенекен итә, ул республикада гына түгел, ә бәлки Россия Федерациясе күләмендә танылу ала. Җәмил Газиз улы Нигъмәтов бүген дә ныклы иярле аргамакта. Фән юлында әйдәп бара, яшьләр күңеленә мәрхәмәтле белем орлыклары чәчә. Аннан аң-белем, тәрбия алган яшь буын вәкилләре, галимнең күңел җылысын хәтеренә салып, республика мәктәпләренә мөгаллимлек итәргә тарала.



*Педагогика – яшәешнең асылына нигезләнгән, борынгыдан ук тамырланган фән. Теләсә нинди төзелешле җәмгыять шартларында да, кеше шәхесен тәрбияләү мәсьәләсе, педагогик проблемалар яшәешебезнең үзәгендә торачак. Җәмгыятебез аларның мөһимлеген ни дәрәҗәдә аңлый, ни дәрәҗәдә һәм ничек хәл итәргә омтыла – андагы тормыш, яшәеш һәм көнкүреш тә шуңа карап билгеләнә. Менә шушы табигый хакыйкатьне дөрес аңлаган шәхесләрнең берсе ул – Җәмил Газиз улы Нигъмәтов!*

*Мәгариф өлкәсендәге зур хезмәтләре, педагогика тарихын һәм теориясен үстерүгә керткән өлеше өчен, Америка биография институты Җ.Г.Нигъмәтовны «1997 ел кешесе» дип игълан итә һәм биографиясен Халыкара Кембридж үзәгендә (Англия) нәшер ителә торган «Кто есть кто в мире» дигән атаклы кешеләр турындагы китапның унөченче томына кертә.*



*Галим бала чагында артист булу турында да хыялланган. Ул бүген бу хыялы да тормышка ашкан дип саный. Укытучы, мәктәп директоры булган вакытта ул сәхнәдән төшми. Төрле спектакльләрдә катнаша, акробатик чыгышлар ясый, матур итеп бии, моңлы, озын татар җырларын сузып җибәрә. Беренче тапкыр яңа фатир алгач, өйгә алып кайткан иң беренче мебеле пианино була. Шигырьләр иҗат итү белән дә мавыга.*

• Тәңгә - мунча, җангә - юк

Соңгы арада ди-джей профессиясе бик популяр. Винил осталарына карап, төрле кичә-бәйрәмнәр романтикасына ушлары китеп, мәктәп укучылары да ди-джей һөнәренә өйрәнергә тели. Моңа бер дә аптырыйсы түгел, чөнки ди-джейлар, чын мәгънәсендә, теләсә нинди чараның бию мәйданы йолдызы, кичәләрнең төп геройлары, яхшы кәеф тудыручы тылсымчылары булып торалар. Күп яшьләр өчен бу һөнәр хыялларның хыялы булып кала.

# Кем ул ди-джей?

**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

Үз ритмыңны булдырып, аны тотып алырга ашкынып чыккан яшьләр «көтүе»н биетүдән дә яхшырагы бармы соң? Игътибар үзәгендә булганың өчен акча аласың, кичәләрдә күңел ачасың, ди-джей дигән сүзне ишеткән яшь кызлар дулкынлана башлый – болар, чыннан да, дөрес. Һөнәр катлаулы да түгел төсле. Яраткан көйләрне куеп баруның ни авырлыгы бар? Тик бу беренче карашка гына. Ди-джей бер композицияне куйганда, колакчыннары аша ул инде монысыннан соң яңгыраячак башка музыканы тыңлый, аннан шул ике көйне, ритмнары буенча туры китереп, синхронлаштырырга һәм бербөтенгә әйләндерергә тиеш. Шул очракта бер агымдагы музыка барлыкка килә. Ди-джейның төп эше нәкъ шуңарда чагыла да. Аннан бигрәк, музыкаль слух (ишетү) һәм техника белән эш итү мөһим. Яхшы хәтер дә әһәмиятле. Чөнки исәпсез-сансыз музыкаль өзекләрне, җырларны хәтердә калдырырга кирәк. Андый музыкаль хәтер еллар үтү белән генә килә. Яңалыклар белән кызыксыну, гаять зур күләмдә төрле-төрле музыка тыңлау да аның эше.

## Кире яклары

Сәламәтлектән башлыйк. Берәрегезнең ди-джейны көн яктысында күргәне бармы? Сирәктер. Шау-шулы эш төненнән соң йокы туйдыру белән дә бәйле түгел бу. Чынында исә, аларның хәлләре көндез бик мөшкел була. Шуңа өйләрендә җәнлекләр сыман посып яталар.

Ишетү сәләте белән проблемалар барлыкка килергә мөмкин. Гадәттә, ди-джейның аппаратурасы дөбер-шатыр килгән колонкаларянындаурнашкан, анда инде нинди көчле тавыш яңгыраганын һәркем белә. Британиядә хәтта махсус программа буенча тавышсыз дискотекалар оештырганнар. Биергә теләүчеләр чыбыксыз наушниклар киеп бии. Британиянең Above&Beyond төркеме егетләре исә, сәхнәгә берушисыз (беруши – махсус колакчыннар) чыкмый да икән.

Куе төтен (тәмәкедән дә, төтен машиналарыннан да), даими рәвештә җемҗем итеп торган стробоскоплар, күзгә бәрүче төрле төстәге лазерлар, һәрчак тонык ут – боларның барысы да берничә ел актив концерт эшчәнлегеннән соң ди-джейның сукыраюына китерергә мөмкин.

## Карт һөнәрме?

Беренче тапкыр диск-жокей сүзен 1935 елда Америка комментаторы Уолтер Уинчелл яңгырата. Ул бу сүзне беренче ди-джей, радиотапшырулар алып баручы Мартин Блокка карата куллана. Соңрак бу сүзтезмә DJ аббревиатурасы буларак языла башлый, ди-джей эше исә, ди-джеинг дип атала. Яхшы билгеле ди-джейларның берсе Томас Лодж 1964 елда беренче тапкыр ди-джей һәм Бөек Британиянең Радио Каролина беренче оффшор пират радиостанциясе тапшырулары директоры була. Ул «Дөньяны селкеткән кораб» («Корабль, который покачнул мир») исемле китабында анда үткәргән вакытны тасвирлый. Ди-джей буларак, Лодж әле ул кадәр билгеле дә булмаган Битлз төркеменнән эксклюзив интервью ала. Кайчандыр Пол Маккартни, ди-джей Лодж үзенең хезмәте өчен рыцарь титулы алырга тиеш иде, дигән фикер дә белдергән.


Айсылу


Алисә


Айваз

## Ничек ди-джей булдыгыз?

• ***Алисә Җамалиева:*** «2012 елның сентябрендә «Татар радиосы»ннан кастинг турында ишеткәч, радионың автоҗавап кайтаргычына шалтыратып, үзем турында мәгълүмат калдырдым, тик бер айлап радиодан бер хәбәр дә булмады. Ниһаять, бар үҗәтлегемне җыеп: «Нишләп әле миңа шалтыратмыйлар?» – дип, үзем элемтәгә чыктым. Шуннан соң эфирларга чакыра башладылар һәм эшкә дә алып куйдылар. Паралель рәвештә 2 югары уку йортында укып эшләгәч, кайчакларда бераз авыррак та булды, тик эфирга килгәч, барлык борчу-мәшәкатьләр онытыла кебек».

• ***Айсылу Лерон:*** «Бер ямьле җәй көнне, көтмәгәндә радиодан шалтыратып, тавышымны яздырып карарга чакырдылар. Аннары эшкә дә алдылар. Беренче эфирым әле дә истә... Булат Бәйрәмов белән төнге тапшыруны бергә алып бардык, ул мине эш пультының иң кирәкле төймәләре белән таныштырып чыкты. Икенче тапкыр Әбри Хәбриев белән эшләдек, алга таба инде эфирга үзем генә чыктым».

• ***Айваз Садыров:*** «Кечкенәдән радиода эшләячәгемне белдем. Өченче класста, ике магнитофон кушып, берсенә җырлар куеп, икенчесенә яздырып, өйдәгеләргә сәлам җибәреп утырганым хәтердә. Аннары, укырга кергәч, Арча радиосына кунакка йөри башладым, ничек эшләгәннәрен күзәтеп, алып баручылар белән таныштым. Шул елларны «Яшьләр радиосы» дип аталган интернет радио да ачып җибәрдем. Алга таба Арча радиосында эшләп алдым, аннары «Татар радиосы»на юл тоттым. Миннән киңәш: хыялланыгыз».

• Башваткыч

**Зөлфия ЗАРИПОВА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

## Башваткыч сораулары:

**1**. Казан федераль университетының архитектур ансамблен төзегән кеше.
**2**. 1844 нче елда яңа химик элемент ачкан галимнең фамилиясе.
**3**. Университет 1795 нче елда төзелгән әлеге бинада ачыла.
**4**. Хәзер ул 1 сәгать тә 30 минут бара.
**5**. Күренекле астроном, Антарктиданы ачучыларның берсе, 1846 – 1854 нче елларда Казан университеты ректоры.
**6**. Казан Университеты тарихы музее булдыру турындагы беренче фикер әлеге газетада чыга.
**7**. Астроном, 1899 – 1905 нче елларда университетның ректоры. Аның хөрмәтенә айдагы бер кратерга аның исеме бирелә.
**8**. Лобачевский исемендәге китапханәнең нигезен әлеге кенәзнең китаплар җыентыгы тәшкил иткән.
**9**. Фосфорорганик тоташмалар химиясен ачкан галим – химик.
**10**. Бу кешене 2010 нчы елның 9 апрелендә Казан Федераль университетының ректоры итеп билгеләделәр.
**11**. Бөек математик, 1827 – 1846нче елларда университетның ректоры булып торган, университет үсеше өчен күп эшләгән галим.
**12**. Акчуриннар нәселенең бер вәкиле. Узган гасырның 20 нче еллары уртасында Казан университетының медицина факультетында укыган.
**13**. 1989 нчы елда әлеге бина Казан университеты составына керә.
**14**. Казан университетының тарихы музееның беренче ядкаре Н.И.Лобачевскийның кечкенә мөһере була. Аны музейга тапшырган профессорның фамилиясе.
**15**. Казан Федераль университетында алар 18.
**16**. Фундаменталь медицина һәм биология институтының 2 бинасы бар. Берсе Карл Маркс урамында, икенчесе кайсы урамда.
**17**. Н.И.Лобачевский геометриясе әлеге геометриядән аерылып тора.
**18**. Карл Карлович Клаус уйлап тапкан химик элементның исеме.
**19**. Әлеге мәктәпне И. А. Бодуэн де Куртенә нигезли.
**20**. XIX гасырның 20 нче елларында әлеге архитектор Казан университетының төп бинасын төзи.
**21**. Күренекле галим А.Ф. Самойлов әлеге мәктәпкә нигез сала.
**22**. Казан химия мәктәбен бөтен дөньяга танытkan галим.




Башваткычның җавапларын киләсе санда укыгыз.

• Белми калма!

**ТАТАР ҖЫРЫН СӨЮЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА!**

Казан федераль университеты каршындагы **ТАТАР ХАЛЫК ХОРЫ** Сезне үз сафларына чакыра.

Бирегә Сез солистлар буларак та, вокаль төркемнәрдә дә чыгыш ясый алачаксыз.

Җырларга теләүчеләрне кабул итү:
Дүшәмбе: 17.00-20.30
Чәршәмбе: 17.00-20.30
Безнең дәресләр:
Сишәмбе: 17.00-20.30
Пәнҗешәмбе: 17.00-20.30
Җыелу урыны: университетның төп бинасындагы 2нче физ. аудитория (245 ауд.)

РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
КӨТЕП КАЛАБЫЗ!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.